


Чынлап та бу кечкенә йолдызчык турында язар очен нинди каләм, нинди дорес сvзләр кирәк икән?!
Нинди йолдызчык дип сорарсыз?
«Шумбрат, Мордовия!» дигән XXI рес-публика фестивалендә катнашучы дvрт яшьлек Диана Тумпарова жыры белән халыкны тан калдырды. Ул фестивальнен барлык ярыш этапларын жинә-жинә, Гала-концертына кадәр житте.
Тамашачы Диана Тумпарованы халык койләрен оста башкаручы буларак кабул итте. Дvрт яшендә булуына карамастан, анын концерт залларында әбисе - Атюрьево артисткасы Надежда Карпина белән чыгышлары артканнан-арта бара. Мәсәлән, концерт программаларында унышлы Темниково, Торбеево, Краснослабодск районнары Мәдәният йортларында жырнын тәмен, кадерен белгән зәвыкълы тамашачы алдында чыгышлары бар инде анын.      Дианада тоемлау, сизә белv бик кочле. Бишектә чакта ук койләр чыгара торган булган. Ул тамашачыга, жинел янгырашлы койләрне, заманча ритмнарны, берсе артыннан берсен тезеп бара ала. Атюрьевочылар концерты программасынын «кадагы» булган дvрт яшьлек Диананын «Чибатуха» жыры белән фестивальдә чыгышы булды. Бубенын кирәк урында уйнатып, шул арада биеп тә алды. Сок-ланып карап торды тамашачы кечкенә «йолдызчык»ка. Инде кvпме мәртәбәләр тынласан да, тынлыйсы гына китеп тора аны. Репертуары уйланган, һәр хәрәкәт, һәр адым vлчәнгән. Дvрт яшьлек дип тә димәссен. «Шумбрат, Мордовия!» фестивале Гала-концертында Мордовия Главасы

